**Яхшылык җирдә ятмый.**

Максат:
1.Кешелеклелек, шәфкатьлелек сыйфатлары тәрбияләү.
2.Шәфкатьле кешеләрнең эшләре белән танышу, аларныүзеңә өлге итеп алу.
3.Киләчәктә үз балаларын шәфкатьле итеп тәрбияләү юнәлешен бирү.
4. Укучыларда кешелеклелек, шәфкатьлелек, ярдәмчеллек, изгелек сыйфатлары тәрбияләү.
Сыйныф алдан бизәлеп куела.Экранда:
"Яхшылык кыл, яхшылыкта бар файда,
Кем яманлык кылса, ул таба җәза."
Слайд2 "Әгәр итсәң бераүгә син изге эш,
Үзеңә дә килер шундый ук өлеш.
"Игелекле эшнең иртәсе-киче юк" кебек плакатлар эленә.
Укучыларның тимурчылык эше буенча язылган иншаларыннан, ясаган рәсемнәреннән стендлар, альбомнар куела.
- Хәерле иртә укучылар.!
Әйдәгез,барыбыз да матур итеп **басып,**кулга-кул тотышыйк, бер-беребезгә елмайыйк та зур итеп кояш ясыйк . Куллардан-кулларга җылылык, күңелдән-күңелгә рәхәтлек йөгерде, йөзләргә якты нур булып елмаю сирпелде. Менә шушы җылылык, рәхәтлек, елмаю безгә көн буена җитәрлек көч бирә дә инде.
. (Барыбыз да урыннарга утырабыз)
Кояш бар җиһанны яктыртучы , без дә бүген үзебез дә кояш ролендә булырбыз.
Кояш кешеләр өчен нәрсә эшли. ?
Гел яхшылык кына эшли!
Димәк без бүгенге тәрбия сәгатендә яхшылык, изгелек һәм шәфкатьлелек турында сөйләшербез. Аларны үзебезнең юлдашыбыз итеп алырбыз.
Слайд3 Татар теленең аңлатмалысүзлегендә яхшылык сүзенең түбәндәге синонимнары бирелгән:

- ✓ Мәрхәмәтлелек
- ✓ Ярдәмчеллек
- ✓ Кешелеклелек
- ✓ Шәфкатьлелек
- ✓ Ихтирамлылык
- ✓ Игелеклелек

Шәфкатьлелек, мәрхәмәтлелек, тәүфыйк - миһербан, игелек- изгелек, ярдәм, киң күңеллелек, кадер-хөрмәт, наз- игътибар, юмартлык, сабырлык, итагатьлелек һам башка матур төшенчәләрне дә үз эченә алучы, бик киң мәгънәле сүз ул.

Димәк, без игелекле эшләрне аеруча күп башкарырга,
туганнарыбыз- якыннарыбыз белән тагын да күбрәк аралашырга, бер- беребезгә игътибарлы, ихтирамлы, түзем, миһербанлы булырга, ятим- мохтаҗларга җан җылысын, матди ярдәмне кызганмаска, изге гамәлләр башкарганда юмартлык күрсәтергә тиешбез..

**Олыны олы ит, кечене кече ит,** дигәннәр борынгылар. Безгә дә бу мәкальнең мәгънәсен онытырга ярамый.Өлкәннәргә, үзебездән кечеләргә, көчсезләргә һәрвакыт, һәркайда игътибарлы,мәрхәмәтле булырга кирәк..Димәк, элек-электән үк игелек, шәфкатьлелек бик тирән мәгънәле сүзләр булганнар. Халыкта игелек кылу зур савап саналган, кылган игелек юкка чыкмый, кире әйләнеп кайта.
.С. Батыршинаның «Трамвайда» исемле шигырен укый.

С. Батыршинаның «Трамвайда» шигыре

Әнә бала- чагалар,
Трамвайда баралар.
Һәммәсе дә утыра,
Карт- коры басып тора.
Алар шундый кап- картлар:
Җыерчыклы яңаклар,

Олыларга ярдәмгә
Ничек килер идегез?
-Яле, Шәүкәт, әйт әле,
Син нәрсә кылыр идең?
-Күрмәмешкә салышып
Укып утырыр идем.
-Ә син, Җәмил, нишләрсең?
Син нәрсә кылыр идең?

Сап- сары йөзләре,
Начар күрә күзләре.
Чуалышкан уйлары,
Дер - дер килә куллары.
Ерак микән аларның
Бара торган юллары?
Ә балалар япь - яшьләр,
Чем - кара шомырт чәчләр,
Ап - алсу яңаклары
Тулып пешкән чаклары.
Шул балалар урынында
Үзегез дип белегез.

-Йоклаганга салышып,
Күземне йомыр идем.
-Ә син, Муса, нишләрсең,
Нинди уйга килерсең?
-Тиз - тиз торып урынымны
Карт әбигә бирермен.
-Хәзер ясыйк нәтиҗә:
Нинди булырга кирәк?
-Муса кебек балалар
Булсын иде күбрәк.

Бер матур сүз кеше күңелендәге бозны эретә ала. Татар халкында мондый мәкаль бар:
Слайд 4. “ Җылы җил боз эретә, җылы сүз җанны эретә”
Кешеләргә генә түгел, табигтькә ,үсемлекләргә һәм хайваннарга карата да игътибарлы булырга һәм яхшылык эшләргә кирәк.
Халкыбызда элек-электән ятимнәргә, гарипләргә, язмыш кимсеткән кешеләргә карата аерым бер гадәт яшәп килә. Аларны кызганганнар, хәлләренә кергәннәр., кулларыннан килгәнчә ярдәм иткәннәр.
Укучылар Сезнең шундый игелекле эш-гамәлләр кылучы кешеләр турында газет-журналдан, я булмаса, телевизордан күргәнегез, ишеткәнегез бармы ?
Игелекле гамәлләре белән Татарстанга гына түгел, чит төбәкләргә дә танылган хәйрияче Әсгать Галимҗанов. Әсгать Галимҗанов Татарстан балаларын гына түгел, Башкортстан, Әрмәнстан балаларын да автобуслар бүләк итеп шатландырган.
Тирә юнебездә изге күңелле кешеләр булуыүзе зур куаныч!
Укучылар үзләренең картлар һәм инвалидлар йортына барып, мәктәпкә өлкәннәрне чакырып, концерт куюлары турында чыгыш ясыйлар.

**Хикәя уку.**

Быел Гөлгенәгә 11 яшь тулды. Башка иптәшләренең уйнаганына, йөгергәненә сокланып һәм кызыгып яши ул. Тумыштан ук бер аягы гарип аның, бер якка кыйшаеп атлавыннан үзе дә уңайсызлана.

Беркөнне гадәттәгечә ул мәктәпкә барырга чыкты. Каршысына очраган этләргә карап, туктап калды, еламсырап артка чигенде. Аның артыннан килеп җиткән Рәшит сызгыра-сызгыра сотовыйдан музыка тыңлап үтеп китте.

- **Рәшитнең бу адымын ничек бәяләр идегез.?**
- Гарип ,инвалид кешеләргә, бәлага таручыларга ярдәм итәргә кирәк.
- **Барыбыз да яхшылыкка мохтаҗ,**
  **Бу заманда бигрәк.**
  **Яхшылыкны эшләү җиңел түгел,**
  **Ә эшләргә кирәк!**

Шәфкатьлелек, яхшылык кебек күркәм сыйфатлар татар халкында иң югары бәяләнгән. Бу изге гамәлләр турында мәкаль һәм әйтемнәр иҗат ителеп, алар еллар дәвамында безне рухи яктан баета, әдәплелеккә өйрәтә.
Слайд5-6

**Укучылар , мин сезгә мәкальләр бирәм, ә сез аларның ахырын табарсыз.**

1. Яхшылык җирдә ятмый.
2. Җылысүз - җан азыгы.
3. Олыны олыит, кечене кече ит.
4. Ашның мае бар, сүзнең җае бар.
5. Яхшы гадәт адәм итәр, яман гадәт әрәм итәр
6. Кеше холкын күзәт- үзеңнекен төзәт.
7. Матурлык эзләмә, яхшылык эзлә.

Укытучы. Шәфкать төшенчәсе белән бәйләнешле нинди мәкальләр һәм әйтемнәр беләсез.
Слайд 7. Укучылар, сез бу мәкальләрне ничек аңлыйсыз?

| | |
|---|---|
| . Кешегә игелек итсәң- үзеңә булышырлар.<br>Изгелек итсәң яшер, изгелек күрсәң фаш ит.<br>Матурлык- бер көнлек, игелек- мәңгелек.<br>Изгелек эшен озакка сузарга ярамый. | Игелекле эшнең иртәсе- киче юк.<br>Изгелек иткән юлда калмас.<br>Изгелек итә алмасаң, яманлык кылма. |

- **Ялган яхшылык** (Кытай әкиятен тыңлату) .

**Тыңланган әкияткә анализ.**

-Әкиятнең соңгы җөмләләре мондый: **Изгелекне дә баш эшләтеп кылырга кирәк. Шәфкатьсез акыл – начар. Ләкин уйланып бетмзгән мәрхәмәтлелек тә – начар була.** Сез аны ничек аңлыйсыз?

- Эшләр нинди булырга тиеш?

- Исегезгә төшерегез, сезнең тормышта да изгелекне теләп эшләгән ләкин соңрак үкенгән эшләрегез булгандыр?

-Нигә болай була ?

- **Сәдаканың зуры-кечкендсе булмый( юлдагы ташны алып куюның сәвабы)**

Дога белмим дисең нигә?
Яхшылык-үзе дога!
Бар кеше изгелек кылса,
Яктырыр иде дөнья.
Изгелек ул-беркайчан да
Тузмый торган хәзинә.
Яхшылык эшлик һәрвакыт**,**
**Ул үзе изге дога**

Йомгаклау.

Укучылар без бүгенге тәрбия сәгатендә нәрсә турында сөйләштек?

Слайд 8 Р.Миңнуллинның “Яхшылык” дигән шигыреннән өзек белән тәмамлыйсым килә!

Яшәү безгә авыр булыр иде
Яхшылыктан башка.
Шуңа күрә яхшылыкны эшлик
Без үзебез башта